| ГЛАВА МАЙНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МАЙНА АВЫЛ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.12.2021 с. Верх.Тат.Майна № 19

**«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Алексеевск муниципаль районының Майна авыл җирлегенең Баганино урман хуҗалыгы поселогында ражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Майна авыл җирлеге Уставы нигезендә

**карар бирәм:**

1. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Майна авыл җирлеге башлыгын билгеләргә.
2. Алексеевск муниципаль районының Майна авыл җирлегенең Баганино урман хуҗалыгы поселогында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 17 декабрендә график нигезендә билгеләргә (Кушымта).
3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Майна авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда үзара салым кертүгә сез, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

- торак пунктларда урамнарны яктырту (урам фонарьлары сатып алу, килешү буенча хезмәт өчен түләү);

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, Майна авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

ӘЙЕ  ЮК».

4. Әлеге карарны Майна авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Майна авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Алексеевск муниципаль районының**
**Майна авыл җирлеге башлыгы** **Р.Н.Гафиятуллин**

Кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының**
**Майна авыл җирлегенең Баганино урман хуҗалыгы поселогында**
**үзара салым кертү мәсьәләсе буенча**
**гражданнар җыенын этаплап уздыру**
**ГРАФИГЫ**

| **Тәртип саны** | **Үткәрү датасы** | **Үткәрү вакыты** | **Үткәрү урыны** | **Урамнарның исеме** |
|---|---|---|---|---|
| **1** | 18 декабрь 2021 ел | 9.00 | ТР, Алексеевск районы, Баганино урман хуҗалыгы пос., Урман ур., 5а й., контора бинасы | 1-нче йорттан 6-нчы йортка кадәр Урман урамы гражданнары чакырыла |